ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль, 2016 ел № 6/8

Шәһәр Советының 2015 елның 9 ноябрендәге «Җир салымы турында» 3/4 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2014 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 473-ФЗ санлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 28 гыйнварендәге «Яр Чаллы» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» 44 санлы Карары, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 9 ноябрендәге «Җир салымы турында» 3/4 санлы Карарына 4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 15 пунктчаны өстәп үзгәрешләр кертергә:

«15) оешмалар – резидентлар «Яр Чаллы» алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлек башкару турында килешү кысаларында инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә, резидентлар реестрына тиешле язу кертелгән көннән 10 елга кадәр срокка.».

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ